КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 23 август г.Казань № 1006

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм боерыкларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керүе тәртибе турында» 2002 ел, 5 сентябрь, 524 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2003 ел, 18 апрель, 212 нче; 2015 ел, 29 сентябрь, 722 нче; 2016 ел, 16 июнь, 408 нче; 2018 ел, 27 ноябрь, 1062 нче, 2019 ел, 25 июль, 621 нче, 2021 ел, 1 октябрь, 943 нче, 2022 ел, 23 июнь, 602 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), преамбулада «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 10 июль, 348 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2013 ел, 2 февраль, 69 нчы; 2013 ел, 24 июнь, 436 нчы; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2016 ел, 20 февраль, 103 нче; 2016 ел, 6 август, 536 нчы; 2017 ел, 15 июль, 497 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче; 2017 ел, 28 декабрь, 1070 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1126 нчы; 2018 ел, 12 май, 350 нче; 2018 ел, 18 май, 375 нче; 2018 ел, 24 июль, 592 нче; 2018 ел, 8 сентябрь, 762 нче; 2018 ел, 13 декабрь, 1127 нче; 2019 ел, 19 апрель, 311 нче; 2019 ел, 25 декабрь, 1192 нче; 2020 ел, 11 февраль, 94 нче; 2020 ел, 17 март, 196 нчы; 2020 ел, 27 май, 429 нчы; 2020 ел, 28 июль, 629 нчы; 2020 ел, 2 октябрь, 902 нче; 2020 ел, 6 ноябрь, 1000 нче; 2020 ел, 30 декабрь, 1259 нчы; 2021 ел, 3 февраль, 48 нче; 2021 ел, 16 июнь, 465 нче; 2021 ел, 29 декабрь, 1311 нче, 2022 ел, 17 сентябрь, 1014 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1460 нчы, 2023 ел, 10 июнь, 709 нчы, 2023 ел, 31 июль, 910 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары структурасы турында» 2005 елның 28 апрелендәге ПУ-147 номерлы Указы белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасы һәм структурасы турында» 2023 елның 4 маендагы 276 номерлы Указы белән» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы турындагы нигезләмәдә «*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«* Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы буенча.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында норма эшләү эшчәнлеген камилләштерү буенча өстәмә чаралар турында” 2008 ел, 31 гыйнвар, 52 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «министрлар һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка башкарма органнары җитәкчеләре» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Башкарма хакимиятнең әлеге органнары каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан фикер алышмыйча кабул ителә алмый торган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлар һәм башка документлар составын раслау турында” 2013 ел, 29 март, 214 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 октябрь, 795 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга, «әлеге башкарма хакимият органнары каршында» сүзләрен «әлеге республика башкарма хакимият органнары каршында» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга, «әлеге башкарма хакимият органнары каршында» сүзләрен «әлеге республика башкарма хакимият органнары каршында» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Республика башкарма хакимият органнарына:»;

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

3 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Башкарма хакимиятнең әлеге органнары каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан фикер алышмыйча кабул

иteлә алмый торган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлар һәм башка документлар составы исемендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «башкарма хакимиятнең республика органнары» сүзләренә, «әлеге башкарма хакимият органнары каршында» сүзләрен «әлеге республика башкарма хакимият органнары каршында» сүзләренә алмаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру буенча вәкаләтле орган турында» 2013 ел, 24 июнь, 436 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 14 гыйнвар, 9 нчы, 2016 ел, 20 февраль, 103 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

5 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

6. Кушымта нигезендә исемлек буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларының үз көчләрен югалтуын танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 23 август, 1006 нчы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының үз көчләрен югалткан актлары исемлеге

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законны Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру барышы хакында» 2006 ел, 31 август, 442 нче карары.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2006 – 2008 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәт стратегиясен гамәлгә ашыру буенча республика программасын раслау турында» 2006 ел, 16 октябрь, 516 нчы карары.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына коррупциягә каршы экспертиза ясау өчен норматив хокукый актлар һәм аларның проектларын тәкъдим итү тәртибен раслау турында» 2007 ел, 20 сентябрь, 474 нче карары.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 24 декабрь, 883 нче карарының 4 пункты.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыкларында закон проекты эшчәнлеге практикасы һәм башкару дисциплинасының торышы турында» 2011 ел, 21 март, 213 нче карары.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 24 октябрь, 1749-б номерлы боерыгы.